КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 16 ноябрь г.Казань № 881

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елда агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 10 февраль, 78 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елда агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 10 февраль, 78 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 1 август, 537 нче; 2017 ел, 14 сентябрь, 671 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2017 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

8 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«җенес буенча бүленгән орлык сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү;

үрдәкләр сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү.»;

9 нчы пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$P_1$ – алучы тарафыннан 2016, 2017 елларда сатып алынган, 2016 елның 1 гыйнвары торышына яки 2017 елның 1 гыйнвары торышына авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесендә булган мөгезле эре ана терлек баш исәбенең 10 процентыннан артыграк булган сөт бирү юнәлешендәге нәселле таналар баш исәбенең тере авырлыгы (сатып алу көненә килограммнарда);»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

«$S_5$ – мөгезле эре терлек сатып алу кыйммәтенең 80 проценты исәбеннән субсидия ставкасы» дигән сүзләрне «$S_5$ – 2016, 2017 елларда сөт бирү юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия ставкасы – 1 килограмм тере авырлыкка 138,0 сум исәбеннән.» дигән сүзләргә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $23^1$ нче һәм $23^2$ нче пунктлар өстәргә:

«$23^1$. Җенес буенча бүленгән орлык сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = P_J \times S,$$

монда:

W – җенес буенча бүленгән орлык сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия күләме;

$P_J$ – 2017 елда алучы тарафыннан сатып алынган җенес буенча бүленгән орлыкның микъдарлар саны;

S – 1 микъдарга 540,0 сум исәбеннән субсидия ставкасы;

$23^2$. Үрдәкләр сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = P_J \times S,$$

монда:

W – үрдәкләр сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия күләме;

$P_J$ – 2017 елда алучы тарафыннан сатып алынган үрдәкләр кыйммәте (сатып алу көненә сумнарда);

S – сатып алу кыйммәтенең 50 проценты исәбеннән субсидия ставкасы.»;

24 нче пунктның беренче абзацында «шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан» дигән сүзләрдән соң «, һәм хайваннарны ясалма орлыкландыру операторларыннан» дигән сүзләрне өстәргә;

29 нчы пунктта:

икенче абзацта «2017 елның 31 мартына» дигән сүзләрне «2017 елның 30 сентябренә» дигән сүзләргә алыштырырга;

алтынчы абзацта «өстәмә» дигән сүзне төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $41^1$ нче һәм $41^2$ нче пунктлар өстәргә:

«$41^1$. 2017 елда җенес буенча бүленгән орлык сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы хайваннарын ясалма орлыкландыру буенча оешмаларга субсидия бирү шартлары – түбәндәгеләр:

алучыларның нәселле терлек буенча дәүләт исемлегендә теркәлү турында таныклыгы булу;

алучылар 2017 елда җенес буенча бүленгән орлык сатып алу.

Субсидия алу өчен алучылар 2017 елда җенес буенча бүленгән орлык сатып алуга шартнамә, исәп-фактура һәм йөкнамә күчермәләрен Нәсел үрчетү эше идарәсенә өстәмә кертә.

41[2]. 2017 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үрдәкләр сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия бирү шартлары – түбәндәгеләр:

2017 елда үрдәкләр сатып алу;

алучыларның 2017 елның 1 гыйнвары торышына үрдәкләре булу.

Субсидия алу өчен алучылар 2017 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең үрдәкләр сатып алуын раслый торган шартнамә, исәп-фактура, йөкнамә күчермәләрен, түләүче банк тарафыннан расланган түләү йөкләмәсен Нәсел үрчетү эше идарәсенә өстәмә кертә.»;

43[2] нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«23[1] нче пункт өчен – сатып алынган җенес буенча бүленгән орлык саны;

23[2] нче пункт өчен – сатып алынган үрдәкләр саны.»;

44 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«44. Татарстан Республикасыннан читтә мөгезле эре терлек (сыерлар, таналар) сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга Нәсел үрчетү эше идарәсе Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән алучыларның шәхси исәпләренә акча күчерүне Идарәләр тарафыннан алучылар яктылыгындагы Татарстан Республикасының муниципаль районы буенча җыелма белешмә-исәп-хисаплар кертелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган сигез көн эчендә гамәлгә ашыра.

Нәсел үрчетү эше идарәсенә Идарәләр тарафыннан кертелгән алучылар яктылыгындагы Татарстан Республикасының муниципаль районы буенча җыелма белешмәләр-исәп-хисаплар субсидияләрне күчерү өчен нигез булып тора.»;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада:

1 нче пунктта «108 648,7» саннарын «185 411,9» саннарына алыштырырга;

4 нче пунктта «14 258,7» саннарын «98,7» саннарына алыштырырга;

5 нче пунктта «10 000,0» саннарын «32 205,0» саннарына алыштырырга;

10 нчы пунктта «4 110,6» саннарын «2 604,8» саннарына алыштырырга;

14 нче пунктта «42 400,0» саннарын «24 400,0» саннарына алыштырырга;

15 нче пунктта «20 000,0» саннарын «10 000,0» саннарына алыштырырга;

таблицага түбәндәге эчтәлекле 16 нчы һәм 17 нче пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «16. | Җенес буенча бүленгән орлык сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 2 160,0 |
| 17. | Үрдәкләр сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 2 000,0»; |

«Барлыгы» дигән юлда «282 592,6» саннарын «342 055,0» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2017 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), шулай ук эшчәнлеген 1 календарь елдан кимрәк гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы оешмаларына туфракларның уңдырышлылыгын саклауга һәм арттыруга

юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

9 нчы пунктта «2017 елның 1 сентябре торышына» дигән сүзләрне «2017 елның 1 ноябре торышына» дигән сүзләргә алыштырырга;

15 нче пунктта «2017 елның 1 сентябре торышына» дигән сүзләрне «2017 елның 1 ноябре торышына» дигән сүзләргә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\881.docx